Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLIV-9**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 22 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгының “Мәгариф”милли проектын тормышка ашыру турында” гы доклады хакында

Россия мәгарифенең глобаль конкурентлык сәләтен тәэмин итү, төп гомуми һәм урта гомуми белем дәрәҗәләрендә укытуның һәм тәрбияләүнең яңа ысулларын кертү максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгының “Мәгариф”милли проектын тормышка ашыру турында” гы докладын игътибарга алырга.

2. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге” МКУенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итәргә тәкъдим итәргә:

- “Мәгариф” милли проектын тормышка ашыру буенча “Юл картасы” эшләү;
- балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү буенча гаделлек, гомумилек принципларына нигезләнгән һәм үз-үзен билгеләүгә һәм барлык укучыларны һөнәри ориентацияләүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле система формалаштыру;
- остазлыкны үстерү өчен шартлар тудыру, иҗтимагый инициативаларга һәм проектларга ярдәм итү, шул исәптән ихтыярыйлык-иреклелек (волонтёрлык) өлкәсендә;
- гражданнарга һөнәри һәм карьера үсеше өчен мөмкинлекләр бирү максатларында һөнәри конкурслар системасын формалаштыру.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов